**Актаныш муниципаль районы**
**Башлыгы Л.Р. Зариповка**

## Актаныш муниципаль районында 2023 елның икенче кварталы өчен гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре турында

2023 елның икенче кварталында район Башлыгына һәм Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә 68 мөрәҗәгать кергән, шуларның 21е (30,9%) интернет-кабул итү һәм электрон почта аша кергән.

Гражданнарның муниципаль район Башлыгына һәм Башкарма комитет җитәкчесенә мөрәҗәгатьләренең тематикасы, нигездә, халыкның социаль һәм икътисадый хәленә кагылышлы сораулар: торак шартларын яхшырту, коммуналь-көнкүреш хезмәте күрсәтү, экология, капиталь төзелеш, халыкны социаль яклау, медицина хезмәте күрсәтү, социаль яклау проблемалары.

Кергән барлык мөрәҗәгатьләрне түбәндәге категорияләргә аерып күрсәтергә мөмкин:

| № | Гражданнар мөрәҗәгатьләре төрләре | Мөрәҗәгатьләр саны | % |
|---|---|---|---|
| 1 | Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау | 10 | 14,7 |
| 2 | Икътисад, сәнәгать | 1 | 1,5 |
| 3 | Төзелеш, архитектура һәм торак шартларын яхшырту, су белән тәэмин итү | 29 | 42,6 |
| 4 | Мәгариф, фән, мәдәният, спорт | 12 | 17,6 |
| 5 | Сәламәтлек саклау | 1 | 1,5 |
| 6 | Транспорт һәм юл хуҗалыгы | 3 | 4,4 |
| 7 | Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек | 4 | 5,9 |
| 8 | Хакимияткә ышанмау | 4 | 5,9 |
| 9 | Җир буенча сораулар | 4 | 5,9 |
| | **БАРЛЫГЫ** | **68** | **100%** |
| 1 | Уңай җавап бирелгән, гражданнар мөрәҗәгатьләре саны | 16 | 23,5 |
| 2 | Аңлатмалар бирелгән, гражданнар мөрәҗәгатьләре саны | 52 | 76,5 |
| | **БАРЛЫГЫ** | **68** | 100% |

Гражданнарның төзекләндерелгән торакка хокукларын гамәлгә ашыру иң кискен һәм социаль әһәмияткә ия проблемаларның берсе булып кала. 2023 елның икенче кварталында торак мәсьәләләре өлеше 42,6% тәшкил иткән (29 мөрәҗәгать).

Халыкны социаль яклау, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты эшчәнлегенең мөһим аспекты булып тора. Социаль яклау учреждениеләренең эше һәр конкрет кешегә максималь якын, аның проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән. 2023 елның икенче кварталында Актаныш муниципаль районы Советы һәм

Башкарма комитетына эшкә урнашу, ташламалар бирү, матди ярдәм күрсәтү мәсьәләләре белән бәйле 10 мөрәҗәгать (14,7%) килде.

Гражданнарны кабул итү графигы расланды. Халык өчен муниципаль район Башлыгы, аның урынбасары, Башкарма комитет җитәкчесе, аның урынбасарлары, структур бүлекчәләр башлыклары гражданнарны шәхси кабул итә. Бердәм кабул итү көне — сишәмбе. Кирәкле документлар (шәхси кабул итү карточкалары яки кайбер бүлекчәләрдә журналлар) законнар нигезендә рәсмиләштерелә. Бүлекчә җитәкчеләре урынбасарлары кабул итүне сишәмбе көннәрендә генә түгел, кирәк булганда алдан язылмыйча да алып баралар. Гражданнарны күчмә кабул итүләр, район җитәкчеләренең халык белән даими очрашулары, "кайнар линия", муниципаль район Башлыгының интернет-кабул итүе эшли.

Кергән барлык мөрәҗәгатьләр контрольгә алынды. 23,5% (16) мөрәҗәгатьләр уңай хәл ителгән.

Шуны билгеләп үтәсе килә, безнең уртак эшебезнең соңгы нәтиҗәсе - район халкына аларның мөһим проблемаларын хәл итүдә ярдәм итү. Һәм бу эшнең халыкның күңелендә аңлау һәм җавап табуы бик сөендерә. Үткәрелгән чаралар халыкны битараф калдырмый. Шуңа күрә җирле үзидарә органнарына карата тәнкыйть мөрәҗәгатьләре саны күп булу белән беррәттән, рәхмәт сүзләре булган күп кенә мөрәҗәгатьләр дә килә.

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитетының
гомуми бүлек башлыгы Л.Г.Хәйдәрова